РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.02.2020 № 159-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 мартындагы 233-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу” муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм “Россия Федерациясендә мәгариф турында Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2019 елның 2 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) топ гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу турында “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентының якынча формасын раслау хакында”гы 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) топ гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу турында “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентының якынча формасына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2020 елның 16 гыйнварындагы 23/20 номерлы боерыгын исәпкә алып, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) топ гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы 2019 елның 18 мартындагы 233-п номерлы карары белән расланган, Саба муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу “Муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1.2. пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ - һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалид калган Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү учреждениеләре һәм органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең, Россия

Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм полициянең махсус исемнәре ия булган затларның балалары, Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ регионы территориясендә террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашучы һәм хокук тәртибен, җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүче, террорчылык оешмалары һәм торкемнәр эшчәнлеген ачыклау һәм булдырмау буенча махсус көчләр составына керүче затлар, Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылык акцияләрен оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучы затлар һәм аларның лидерлары, шулай ук Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр уздыру буенча гаскәрләрнең (көчләрнең) Берләштерелгән төркеме хезмәткәрләре һәм хәрби хезмәткәрләре;

**1.2**. 1.2 пунктының уноченче абзацында “җинаять-башкарма системасы” сүзләреннән соң “Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнарында,” сүзләрен өстәргә;

**1.3**. 1 бүлекнең 1.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Бер гаиләдә яшәүче һәм уртак яшәү урыны булган балалар үзләренең абыйлары һәм (яки) сеңелләре белем алган оешмаларда мәктәпкәчә белем бирүнең топ гомуми белем бирү программалары буенча укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия.”;

**1.4.** 1 бүлекнең 1.8 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ - гариза бирүчеләр белән эшләү өчен бүлмәләрдә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Административ регламентның 1.1, 1.3, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турындагы белешмәләрне үз эченә ала;”;

**1.5**. 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Муниципаль хезмәтнең атамасы | Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына исәпкә кую һәм алу. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында”гы 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.2.Башкарма хакимият органы исеме | Муниципаль хезмәт “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма көмитетының Мәгариф идарәсе” МКУ һәм әлеге административ регламентка 1 кушымтада күрсәтелгән | “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгариф оешмалары тарафыннан күрсәтелә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү очен җаваплы вазыйфаи затлар булып “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ (алга таба - Вәкаләтле хезмәткәр) хезмәткәрләре тора.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар мөрәҗәгать итүчедән, әлеге Административ регламентта каралган мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләр, документлар һәм мәгълүмат алудан тыш, муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле килешүләрне таләп итәргә хокуклы түгел. | |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе булып баланы мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчасының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына алу тора. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында”гы 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:<br>- Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында гаризаны тутырган яисә “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУга кәгазь вариантта гариза биргән вакыттан исәпкә куя өлешендә;<br>- Балаларны оешмага алу өлешендә – Гариза бирүче һәм Оешма арасында килешү төзелгән вакыттан алып. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле | 1. Гариза бирүче баланы исәпкә кую өчен гариза тапшырганда кирәкле белешмәләр исемлеге:<br>- баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме; | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелергә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | - баланың туу датасы;<br>- туу турында таныклык күрсәткечләре;<br>- фактта яшәү урыны (адресы);<br>- ана, ата яисә законлы вәкилләрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, электрон почта адресы, контакт телефоны номеры;<br>- ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен раслаучы документ күрсәткечләре;<br>- белем бирү оешмасына баланы кабул итү буенча ташламалар булуы турында белешмәләр;<br>- баланың сәламәтлеге буенча ихтыяҗы;<br>- бер теләгән оешма;<br>- төркемдә теләгән телдә тәрбия алу һәм уку;<br>- баланы оешмага кабул итүнең теләгән датасы;<br>- теләгән оешмада урыннар булмаганда, башка балалар бакчасы тәкъдименә ризалык/ризасызлык белдерү.<br>2. Баланы оешмага алу өчен кирәкле документлар исемлеге (Гариза бирүче тарафыннан оешмага шәхси мөрәҗәгать иткәндә бирелә):<br>- Оешма җитәкчесе исеменә әти-әниләрнең (законлы вәкилләрнең) язмача гаризасы;<br>- билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе (сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан бирелә);<br>- баланың бер ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ;<br>- психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе (баланы компенсацияләүче һәм катнаш юнәлештәге төркемнәргә керткәндә таләп ителә, психологик-медик-педагогик комиссия тарафыннан бирелә) | белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында"гы 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.6.Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза | Ташламаларны раслаучы документлар:<br>- күп балалы гаилә балалары;<br>- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар балалары;<br>- инвалид балалар; | |

| | | |
|---|---|---|
| бирүче тәкъдим итәргә хокуклы булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | - бер генә эти-әнисе инвалид булган гаиләләр.<br>Документлар социаль яклау территориаль органнары тарафыннан бирелә. | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Исәпкә кую өлешендә:<br>-бала яшенең оешмага кабул ителә торган балалар яшеннән артык булуы.<br>Оешмага алу өлешендә:<br>- “Электрон балалар бакчасы” системасында баланы оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Исәпкә кую өлешендә:<br>- баланың туу турында таныклык мәгълүматларын идентификацияләү процедурасына комачаулаучы дөрес булмаган (җитәрлек булмаган) белешмәләр бирү;<br>- бала яшенең оешмага кабул ителә торган балалар яшеннән артык булуы;<br>- тәрбия алырга һәм укырга теләгән телнең теләгән оешмадага тәрбия бирү һәм укыту теленә туры килмәве.<br>Оешмага алу өлешендә хезмәт күрсәтү түбәндәге очракта туктатыла:<br>- “Электрон балалар бакчасы” системасында баланы оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау;<br><br>Оешмага алу өлешендә:<br>– буш урыннар булмау; | “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында”гы 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтү турындагы гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Шәхси кабул иткәндә чиратта көтү вакыты 15 минуттан да артык булырга тиеш түгел. Әгәр дә хезмәт пенсионерларга, инвалидларга күрсәтелә икән, киләсе Гариза бирүченең көтү (хезмәт күрсәтү) вакыты 30 минутка кадәр озайтылырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать иткән барлык затларны кабул итү эш көне тәмамланырга 1 сәгатьтән дә соңга калмыйча тәэмин ителергә тиеш. | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган | Гариза бирүче “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә исәпкә кую турындагы гаризаны | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең үтенечен, шул исәптән электрон формада, теркәү вакыты һәм тәртибе | теркәү, Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакыттан соң, 1 эш коне дәвамында, Административ регламентның 3 бүлегендә каралган тәртиптә башкарыла.<br>Баланы оешмага кабул итү турындагы гаризаны теркәү, Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакыттан соң, 1 эш көне дәвамында, Административ регламентның 3 бүлегендә каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен бүлмәләрдә муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары урнаштырыла. Бинаның фасад өлешендә муниципаль мәгариф идарәсе органы исеме турында мәгълүмат урнаштырыла.<br>Кабул итүне көтү өчен гариза бирүчеләргә документларны рәсмиләштерү өчен урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырылган урыннар бирелә.<br>Бина санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә җиһазландырылырга тиеш. | "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | - документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан башкарылган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы | "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт электрон рәвештә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында күрсәтелә . (https://uslugi.tatar.ru) | "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

**1.6.** 2 бүлекнең 3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“- мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.”;

**1.7.** 3 бүлекнең 3.3.4 пунктының беренче абзацында “оешмага чираттан тыш, беренче чиратта кабул итү хокукы” сүзләрен “оешмага чираттан тыш, беренче чиратта,өстенлекле рәвештә кабул итү хокукы” сүзләренә алмаштырырга;

**1.8.** 3 бүлекнең 3.6 пунктының өченче абзацында “оешмага чираттан тыш, беренче чиратта кабул итү хокукы” сүзләрен “оешмага чираттан тыш, беренче чиратта, өстенлекле рәвештә кабул итү хокукы” сүзләренә алмаштырырга;

**1.9.** 3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.7 пункты белән тулыландырырга:

“3.7. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта аша “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУга муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Вәкаләтле хезмәткәр мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә һәм кирәк булганда гариза тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, кисәтүләр.”;

**1.10.** 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

**5.1.** Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы таләпне теркәү срокларын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәккә шикаять бирелә торган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне башкару документларын яисә мәгълүматны таләп итү яисә аларны гамәлгә ашыруны таләп итү.;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәккә шикаять бирелә торган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

6) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителгән оешмаларныц вазыйфаи затыныц яисә аларныц хезмәткәрләренец муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда ясалган хаталарын һәм ялгышлыкларын төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнец билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәккә шикаять бирелә торган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенец башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракларда муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү күпфункцияле үзәккә шикаять бирелә торган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче тапкыр кабул итүдән баш тартканда, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елныц 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, аларныц булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүматны таләп итү. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү күпфункцияле үзәккә шикаять бирелә торган карарларга һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин;

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә дәүләт хакимиятенец тиешле органына (җирле үзидарә органына), күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы (алга таба-күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмаларга тапшырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр югары органга (аның булганда) бирелә яисә ул булмаганда, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәренец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күп функцияле үзәкнең

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү очен күпфункцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителгән оешма хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешма җитәкчеләренә тапшырыла.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органныц, муниципаль хезмәт күрсәтүче органныц вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченец шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күп функцияле үзәкнец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнец бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күп функцияле үзәк тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен җәлеп ителә торган оешмаларныц карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнец бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнец региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүченец шәхси кабул итүендә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт корпорацияләре һәм аларныц вазыйфаи затлары, федераль дәүләт хезмәткәрләре, Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күп функцияле үзәкләр тарафыннан җәлеп ителә торган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне бирү һәм карау тәртибе, шулай ук күпфункцияле үзәкнец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

5.5. Федераль закон тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның вазыйфаи затларыныц, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне бирү һәм карау тәртибе (процедурасы) билгеләнгән очракта, әлеге Административ регламентның 5 бүлегендә күрсәтелгән нормалар әлеге шикаятьләрне бирү һәм карау белән бәйле мөнәсәбәтләр өчен кулланылмый.

5.6. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарыныц һәм аларныц вазыйфаи затларыныц, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарыныц дәүләт граждан хезмәткәрләренең, җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнец карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне бирү һәм карау үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

5.7. Шикаять түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүче органныц, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтү очен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмаларның, аларныц җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләренец атамасы, аларныц карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган карарлар һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына);

2) гариза бирүченец фамилиясе, исеме, атасының исеме (соцгысы - булган очракта), гариза бирүченең - физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар, гариза бирүченец - юридик затның урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (булганда).;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органныц, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмаларныц, аларның хезмәткәрләренец шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затыныц яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренец, күпфункцияле үзәк хезмәткәренец, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренец карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәве турында дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда), яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.8. Муниципаль хезмәт, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы органга, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күп функцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмага яисә югары органга (булганда) килгән шикаять аны теркәгәннән соц унбиш эш көне эчендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күпфункцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү очен документлар кабул итүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтүдән яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылуга шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән соц биш эш көне эчендә каралырга тиеш

5.9. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенец норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.10. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.11. Шикаятьне мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләндерергә тиешле дип танылган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен күпфункцияле үзәк тарафыннан җәлеп ителә торган оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга кирәк булган алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.12. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.13. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составының билгеләре билгеләнгән очракта, вазыйфаи зат, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.”;

**1.11.** түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек белән тулыландырырга:

“6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре/

6.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (алга таба - КФҮ) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен КФҮдән документлар килгәндә процедуралар әлеге Административ регламентның 3.4-3.7 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.”;

**1.12**. 1 кушымтаны әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

**1.13**. 3 кушымтаны төшереп калдырырга.

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Саба муниципаль районында
“Мәктәпкәчә белем бирүнең
(балалар бакчаларыныц) төп
гомуми белем бирү программасын
гамәлгә ашыручы мәгариф
оешмаларына балаларны исәпкә
кую һәм алу” муниципаль хезмәт
күрсәтүнең Административ
регламентына 1 Кушымта

**“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетыныц Мәгариф идарәсе” мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмалары турында мәгълүматлар**

| Оешманыц исеме | Җитәкченен фамилиясе,исеме, этисенец исеме | Оешманыц адресы/ сайты | Телефон | Оешманың эш режимы, җитәкченец кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| Олы Кибәче “Күбәләк” балалар бакчасы МБМББУ | Хәбибуллина Сиринә Нургаян кызы | 422065, ТР, Саба муниципаль районы, Олы Кибәче авылы, Ф. Энгельс ур., 75 йорт https://edu.tatar.ru/saby/b-kibyachi/dou | 42-6-39 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 / Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.30, төшке аш 11.00-13.00 |
| Бигәнәй “Акчәчәк” балалар бакчасы МБМББУ | Зәйнетдинова Гүзәл Ибраһим кызы | 422070, ТР, Саба муниципаль районы, Аккүл Бигәнәй авылы, М. Җәлил ур., 24 йорт https://edu.tatar.ru/saby/bigenej/dou | 48-5-01 | дүшәмбе-җомга 7.30-16.30/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.30, төшке аш 11.30-13.00 |
| Олы Арташ “Карлыгач” балалар бакчасы МБМББУ | Җәләлетдинова Гөлсәрия Әхмәтгаян кызы | 422069,ТР, Саба муниципаль районы, Олы Арташ авылы, Үзәк ур., 33 йорт https://edu.tatar.ru/saby/b-artash/dou | - | Дүшәмбе-җомга 7.15-16.15 / шимбә 7.15-15.15/ сишәмбе, шимбә 8.00-16.00 , төшке аш 11.00-13.00 |
| Олы Нырты “Миләшкәй” балалар бакчасы МБМББУ | Каюмова Гөлсинә Хәмит кызы | 422063,ТР, Саба муниципаль районы, Олы Нырты авылы, Г. Тукай урамы, 24 йорт https://edu.tatar.ru/saby/b-nyrty/dou | 45-3-44 | Дүшәмбе - җомга 7.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр; шимбә 7.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр; / сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | 13.00 дән 15.00 сәгатькә кадәр |
| Олы Шыцар “Әллүки” балалар бакчасы МБМББУ | Сәхипова Лилия Рәүф кызы | 422054, ТР, Саба муниципаль районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив ур., 33 йорт https://edu.tatar.ru/saby/b-shinar/dou | - | дүшәмбе - җомга 6.45-17.15, шимбә 6.45-16.15/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.30, төшке аш 11.00-13.30 |
| Саба муниципаль районы Олы Шыцар “Әллүки” балалар бакчасы филиалы МБМББУ – “Оет балалар бакчасы” | | 422054, ТР, Саба муниципаль районы, Оет авылы, Ленин ур., 38 йорт | 41-3-87 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00 |
| Югары Симет “Акчәчәк” балалар бакчасы МБМББУ | Закирова Алинә Фердинат Кызы | 422055, ТР, Саба муниципаль районы, Югары Симет авылы, Совет ур., 30 йорт https://edu.tatar.ru/saby/v-simet/dou | 45-0-48 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә, 7.00-15.00 / сишәмбе, пәнҗешәмбе 9.00-15.00, төшке аш-11.00-13.00 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет “Акчәчәк” балалар бакчасы филиалы МБМББУ - “Түбән Симет балалар бакчасы” | | 422055, ТР, Саба районы, Түбән Симет авылы, Ленин ур., 60 йорт | 45-1-06 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00 |
| Мишәбаш “Лалә” балалар бакчасы МБМББУ | Маликова Зәлия Ринат Кызы | 422053,ТР, Саба муниципаль районы, Мишәбаш авылы, Г. Тукай ур., 21 йорт https://edu.tatar.ru/saby/meshabash/dou | 46-7-53 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30, шимбә 7.00-16.30, Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, |
| Югары Шытсу “Ак каен” балалар бакчасы МБМББУ | (вакытлыча җитәкче вазыйфасын башкаручы) Гыйлемханова Рәфисә Нурулла кызы | 422067, ТР, Саба муниципаль районы, Югары Шытсу авылы, Ленин ур., 31 йорт https://edu.tatar.ru/saby/v-shitcy/dou | 46-4-52 | Дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00/ сишәмбе, шимбә 8.00-15.00, төшке аш 11.00-13.00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ике Басу Арташ “Күбәләк” балалар бакчасы МБМББУ | Әгъләмҗанова Рәмзия Васыйл кызы | 422069, ТР, Саба районы, Ике Басу Арташ авылы,Г.Тукай урамы, 55 йорт https://edu.tatar.ru/saby/2-pole-artash/dou | 44-8-73 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00,/ сишәмбе, шимбә 8.00-11.00, 13.00-15.00 сәгатьләрдә, төшке аш 11.30-13.00 |
| Явлаштау “Акчәчәк” балалар бакчасы МБМББУ | (вакытлыча җитәкче вазыйфасын башкаручы) Багутова Нәзирә Миннәхмәт кызы | 422053, ТР, Саба муниципаль районы, Явлаштау авылы, Ш. Бариев ур., 21 йорт https://edu.tatar.ru/saby/evlashtau/dou | 46-8-14 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00, / дүшәмбе-шимбә 7.00-16.00, төшке аш 11.00-13.00 |
| Иштуган “Каенкай” балалар бакчасы МБМББУ | Андреева Марина Александровна | 422050, ТР, Саба районы, Иштуган т.ю.р. бистәсе, Үзәк ур., 11 йорт https://edu.tatar.ru/saby/ishtugan/dou | 42-0-22 | дүшәмбе - җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.00-13.00 |
| Эзмә “Саф чишмә” балалар бакчасы МБМББУ | Моратова Эльмира Шәүкәт кызы | 422052, ТР, Саба муниципаль районы, Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт https://edu.tatar.ru/saby/izmya/dou/doska | 4-91-15 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30, шимбә 7.00-16.30 / сишәмбе, җомга 7.30-17.00 төшке аш 11: 30-13:00 |
| Иске Икшермә “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Йосыпова Нәсимә Зөфәр кызы | 422066, ТР, Саба муниципаль районы, Иске Икшермә авылы, Октябрь ур., 23 йорт https://edu.tatar.ru/saby/s-ikshurma/dou | 41-7-70 | 7.30-16.30 - сишәмбе, шимбә 8.00-15.00 төшке аш 11.00-13.00 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә “Кояшкай” балалар бакчасы филиалы МБМББУ – “Татар Икшермәсе балалар бакчасы” | | 422066, ТР, Саба районы, Татар Икшермәсе авылы, Гагарин ур., 19 йорт | 41-8-12 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00 |
| Кызыл Мишә “Ак чәчәк” балалар бакчасы МБМББУ | Тагирова Людмила Ивановна | 422057, ТР, Саба районы, Кызыл Мишә авылы, Ленин ур., 33 йорт https://edu.tatar.ru/saby/k | 43-5-67 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00/ Сишәмбе, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | -mesha/dou | | Пәнҗешәмбе-<br>8.00-16.00,<br>төшке аш 11.00-<br>13.00 |
| Килдебәк “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Мөхлисова Гүзәл Хәмит кызы | 422071, ТР, Саба муниципаль районы, Килдебәк авылы, Мәктәп ур., 222 йорт https://edu.tatar.ru/saby/k-mesha/dou/kildebyak/dou | 45-5-28 | дүшәмбе-җомга<br>7.00-7.30,<br>шимбә<br>7.00-16.30,/<br>Сишәмбе,<br>Пәнҗешәмбе<br>8.00-16.00,<br>төшке аш 11.00-<br>13.00 |
| Курсабаш “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Шәрәфиева Алсу Рафаил кызы | 422051 ТР, Саба районы, Курсабаш авылы, Школьная ур., 26 йорт https://edu.tatar.ru/saby/korsabash/dou | 49-7-30 | дүшәмбе-җомга<br>7.00-16.00, шимбә<br>7.00-15.00,<br>Сишәмбе,<br>Пәнҗешәмбе<br>8.00-16.00,<br>төшке аш 11.00-<br>13.00 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш “Кояшкай” балалар бакчасы филиалы МБМББУ – “Түбән Утар балалар бакчасы” | | 422051.ТР.Саба районы, Түбән Утар авылы.Киров ур., 1 йорт | 49-7-96 | дүшәмбе-җомга<br>7.00-16.00, шимбә<br>7.00-15.00 |
| Лесхоз “Ләйсән” балалар бакчасы МБМББУ | Габдрахманова Гүзәл Файсал кызы | 422062, ТР, Саба районы, Лесхоз бистәсе, Мицнеханов ур., 1 йорт https://edu.tatar.ru/saby/leshoz/dou | 44-2-34 | дүшәмбе-җомга<br>6.30-17.00,<br>Шимбә<br>6.30-16.00/<br>Сишәмбе,<br>Пәнҗешәмбе<br>8.00-17.00,<br>төшке аш 11.00-<br>13.00 |
| Мамалай “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Хәйруллина Айгөл Фәрит кызы | 422070, ТР, Саба районы, Мамалай авылы, Чапаев ур., 6 йорт https://edu.tatar.ru/saby/mamalaevo/dou | 46-5-32 | Дүшәмбе-җомга<br>7:30-16: 30,<br>Шимбә<br>7:30-15:30/<br>Сишәмбе,<br>Пәнҗешәмбе<br>8.00-16.30,<br>төшке аш 11: 00-<br>13: 00 |
| Түбән Шытсу “Акчәчәк” балалар бакчасы МБМББУ | Хәбибрахманова Рәмзия Васыйл кызы | 422067, ТР, Саба районы, Түбән Шытсу авылы, Тукай ур., 1а йорты https://edu.tatar.ru/saby/n | | дүшәмбе-җомга<br>7.00-16.00 /<br>сишәмбе, шимбә<br>8.00-15.00, төшке<br>аш 11.00-13.00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | -shittcy/dou | | |
| Яңа Мичән “Каенкай” балалар бакчасы МБМББУ | Садикова Гүзәл Сәхиулла кызы | 422055, ТР, Саба районы, Яңа Мичән авылы, Ленин ур., 28 йорт https://edu.tatar.ru/saby/n-michman/dou | 4-24-33 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.00-13.00 |
| Олыяз “Чәчкә” балалар бакчасы МБМББУ | Биктина Алинә Давыд кызы | 422050, ТР, Саба муниципаль районы, Олыяз авылы, Ленин ур., 27 йорт https://edu.tatar.ru/saby/oluyaz/dou | 4-95-83 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30, шимбә 7.00-16.30/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.00-13.00 |
| Байлар Сабасы ш. т. б.нең 1 номерлы Саба “Шатлык” балалар бакчасы МБМББУ | Зарипова Рушания Гыйлемхан кызы | 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Мәктәп ур., 39А йорты https://edu.tatar.ru/saby/dou1 | 2 32 43 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 сәгать /сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11: 30-13:00 |
| Байлар Сабасы ш. т. б. нең 2 номерлы Саба “Әллүки” балалар бакчасы МБМББУ | Хәлиуллина Гүзәл Нурулла кызы | 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Закир Йосыпов ур., 4 йорт https://edu.tatar.ru/saby/dou1/dou2 | 2-31-43 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 сәгать /сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11: 30-13:00 |
| Саба ш.т.б.нең 3 номерлы Саба “Шоколад” гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы МБМББУ | Сабирова Эльвира Фәрит кызы | 422060, ТР, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Мир ур., 455 йорт https://edu.tatar.ru/saby/page1819448.htm/page2018420.htm | 2-26-80 | дүшәмбе-җомга 7.00 - 17.30 сәгать /сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11: 30-13:00 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы ш. т. б.нең 3 номерлы “Шоколад” гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы филиалы МБМББУ – “Урта Саба балалар бакчасы” | | Саба муниципаль районы, Урта Саба авылы. Такташ ур., 4 йорт | 2-23-10 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Байлар Сабасы ш. т. б.нең 4 номерлы “Кыңгырау” гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы МБМББУ | Фәйзрахманова Рузалия Фәрих кызы | 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Г. Закиров ур., 54 йорт https://edu.tatar.ru/saby/dou4 | 2 45 85 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 сәгать /сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11: 30-13:00 |
| Саба 5 номерлы “Бәләкәч” гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы МБМББУ | Ахунова Гөлзилә Мәсхүт кызы | 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Пушкина ур.,15а йорты https://edu.tatar.ru/saby/page394398.htm | 2 25 03 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 сәг. / сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11:30-13: 00 |
| Саба 6 номерлы “Балачак” гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы МБМББУ | Хәлилова Флюзия Рафаил кызы | 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Вахитова ур., 24 йорт https://edu.tatar.ru/saby/page2493723.htm | 2 23 20 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 сәгать / сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11: 30-13:00 |
| Сатыш “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Бәдертдинова Сәрия Якуп кызы | 422070, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Сатыш авылы, Кутузов ур., 1 йорт https://edu.tatar.ru/saby/satyshevo/dou | 48 5 03 | дүшәмбе-җомга: 7.00-17.30, шимбә: 7.00-16.30 / сишәмбе-пәнҗешәмбе 8: 00-16: 30; төшке аш 11.00 - 13.00 |
| Иске Мичән “Таң” балалар бакчасы МБМББУ | Шәйхлисламова Гүзәлия Габделнәкыйп кызы | 422055,Татарстан Республикасы,Саба муниципаль районы,Иске Мичән авылы, Мәктәп урамы, 12 йорт https://edu.tatar.ru/saby/st-michan/dou | 42 4 79 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-16.00, Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00 төшке аш 11.00-13.00 |
| Сабабаш “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Хафизова Дамира Каниф кызы | 422062,Татарстан Республикасы,Саба муниципаль районы, Сабабаш авылы, Школьная ур., 11 йорт https://edu.tatar.ru/saby/sababash/dou | 44 5 38 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00, Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Тимершык “Кояшкай” балалар бакчасы МБМББУ | Фазылова Гүзәл Хәсәнша кызы | 422057, ТР, Саба районы, Тимершык авылы, Пионерская ур., 13 йорт https://edu.tatar.ru/saby/t | 2-28-01 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30, шимбә 7.00-16.30/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | imershik/dou | | 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Шекше “Акчарлак” балалар бакчасы МБМББУ | Галимова Зилә Әбрар кызы | 422053,ТР.Саба районы, Шекше авылы, Мәктәп ур., 4 йорт https://edu.tatar.ru/saby/shikshi/dou | 46-1-18 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, Шимбә 7.00-15.00,/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше “Акчарлак” балалар бакчасы филиалы МБМББУ –“Сәрдә балалар бакчасы” | | 422053,ТР, Саба районы.Сәрдә авылы, Мәктәп ур., 5 йорт | 2-26-48 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00 Шимбә 7.00-15.00 |
| Шәмәрдәннең 3 номерлы “Салават күпере” гомуми үстерү төрендәге балалар бакчасы МБМББУ | Әдгамова Гүзәл Рафис кызы | 422050, ТР Саба районы, Шәмәрдән авылы, Һади Такташ ур., 1 йорт https://edu.tatar.ru/saby/shemordan/dou | 3 -25- 92 | дүшәмбе-җомга 7.00 - 17.30 сәг. / Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Юлбат “Акчәчәк” балалар бакчасы МБМББУ | Кадыйрова Гөлназ Гаяз кызы | 422077, ТР, Саба муниципаль районы, Юлбат авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт. https://edu.tatar.ru/saby/yulbat/dou | | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00, Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат "Акчәчәк” балалар бакчасы филиалы МБМББУ – “Йосыф-Алан балалар бакчасы” | | 422077, ТР, Саба муниципаль районы, Йосыф-Алан авылы, Т.Хаҗиәхмәтов ур., 24 йорт. | 43-7-93 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00, /Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Туктар “Тамчы” балалар бакчасы МБМББУ | Ибәтуллина Фәридә Бәдегетдин кызы | 422071, ТР, Саба муниципаль районы, Туктар авылы, Совет ур., 35а йорты https://edu.tatar.ru/saby/timershik/dou/tuktar/dou | 45-5-36 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00/ сишәмбе, шимбә 8.00-15.00, төшке аш 11.30- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | 13.00 |
| Мингәр “Сәйлән” балалар бакчасы МБМББУ | Ибраһимова Дилә Разиф кызы | 422057, ТР, Саба муниципаль районы, Мингәр авылы, Г. Тукай ур., 29 йорт https://edu.tatar.ru/saby/meshabash/dou/minger/dou | 43-1-80 | дүшәмбе-җомга 7.00-16.00, шимбә 7.00-15.00/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-14.00 |
| Иләбәр “Умырзая “ балалар бакчасы МБМББУ | Дәүләтшина Венера Наил кызы | 422052, ТР, Саба муниципаль районы, Иләбәр авылы, 8 Март ур., 53 йорт https://edu.tatar.ru/saby/page1573498.htm | 49-2-33 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30, шимбә 7.00-16.30,/ Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Шәмәрдән 1 номерлы “Әкият” балалар бакчасы МБМББУ | Давыдова Гөлнара Наил кызы | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Газовиклар ур., 1а йорты https://edu.tatar.ru/saby/page1819448.htm | 3-25-39 | дүшәмбе-җомга 7.00-17.30 сәг. / Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |
| Шәмәрдән 2 номерлы «Теремок” балалар бакчасы МБМББУ | Кәримова Гөлнара Рауль кызы | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Яшьләр ур., 15а йорты https://edu.tatar.ru/saby/page2493723.htm/page2493726.htm | 3-22-77 | дүшәмбе-җомга 7.00 - 17.30 сәг. / Сишәмбе, Пәнҗешәмбе 8.00-16.00, төшке аш 11.30-13.00 |

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар турында белешмәләр**

| Вазыйфаи затның фамилиясе/исеме/ әтисенең исеме | Вазыйфасы | Оешманың адресы/сайты | Телефон | Оешманың эш режимы, вазыйфаи затның кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| Гомәрова Луиза Мәҗит Кызы | Баш белгеч | https://edu.tatar.ru/saby/saba, http://imcsaba.3dn.ru/ | 8(84362) 2-40-77 | Дүшәмбе-җомга 8.00-16.30 төшке аш 11.30-13.00/ сишәмбе 13.00-16.30 чәршәмбе 8.00-11.30 пәнҗешәмбе 13.00-16.30 |